*сентябрь, 2021 ел*

# Гимназия сулышы №1

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

## Яңа уку елы уңышлы булсын, дуслар !

1нче сентябрьнең кояшлы иртәсендә беренче сыйныф укучылары рәт-рәт булып тезелде. Белем бәйрәме уңаеннан гимназиянең иң яшь укучыларын шәһәр башкарма комитеты рәисе Зарифуллин Рөстәм Таһир улы котлады. Бәйрәмдә матур җырлар, дәртле биюләр яңгырады. Беренчеләр үз чираты




нда тырышып укырга сүз бирделәр. Беренче кыңгырау яңгырауга укучылар беренче дәрескә киттеләр.

Кадерле укучылар һәм укытучылар! Белем бәйрәме белән !

**БДИ ны 100 баллга!**

Инглиз телен гимназиядә иң яхшы белүче кем ул? Ул- Фәйзрахманова Рузилә. Инглиз теленнән БДИ ны 2021 нче



елда Рузилә 100 баллга тапшырды. Афәрин, Рузилә! Котлыйбыз!

Гимназиянең югары категорияле инглиз теле укытучысы Коновалова Наилә Зөфәр кызы әйтүенчә, Рузилә 9-11 сыйныфларда укыганда инглиз теле буенча Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабында призер һәм җиңүче булды. Билгеле, бу укытучы һәм аның укучысының уртак тырышлыгы нәтиҗәсе.

Бүгенге көндә Рузилә Казан Федераль университетына караган Чит илләр бәйләнеше институтының лингвистика факультетында укый.

Уңышлар сиңа, Рузилә!

Потапова Екатерина

**Укытучыларга бәйрәм котлавы!**




**Хөрмәтле укытучылар! Сез дөньядагы иң авыр һәм мактаулы хезмәтне башкарасыз! Балаларга белем һәм тәрбия бирүдә көчегезне дә, вакытыгызны да кызганмыйсыз!**

**Боекмас өчен күңелләр, кимсенмәс өчен йөрәк – Сез кирәк, укытучылар, безгә һәрчак Сез кирәк!**

## Әтиләр ярышты

16 нчы октябрьдә гимназиянең спорт мәйданчыгында « Әтиләр көне» нә багышланган спорт ярышлары үткәрелде.



5 нче сыйныфларның малайлар һәм әтиләр командалары ГТО төрләре ( йөгерү, аркан тарту ) буенча үзара көч сынаштылар. Укучылар, чарага килгән әти-әниләр аларга кул чабып, көч биреп тордылар . Исламова Карина



## Спектакль карадык



Без бер төркем 5 сыйныф укучылары  шәһәрнең музыка училищесында «Петя маҗаралары» дигән спектакль карадык. Петя һәм башка



геройлар белән бергә юл йөрү кагыйдәләрен кабатладык. Юлда төрле күңелсез хәлгә калмас өчен юл билгеләрен дә белергә кирәк бит.

Артистларның сәхнәдә уйнавы безгә бик ошады.

Афанасьева Вероника

## Минем җәйге ялым



Һәр җәйне мин лагерьда ял итәргә яратам. Быел да « Ялта-Зәй» балалар өчен ял лагерена бардым, әмма әйдаман (вожатый) булып. Яшьтәшләрем рәхәтләнеп ял иткәндә, мин лагерьда ял итүче балалар белән эшләдем: концертлар, квест-уеннар,



кичке уеннар оештырдым. Лагерьда короновируска каршы таләпләр буенча, смена саен тест бирергә туры килде. Өч ай дәвамында балалар белән эшләү миңа үземне һәрьяклап үстерергә, нәрсәгә сәләтле икәнемне аңларга ярдәм итте. Балалар белән эшләү кызыклы, шул ук вакытта бик җаваплы. Миңа быелгы ялым бик ошады.Татарстанның төрле төбәкләрендә яшәүче яңа дуслар таптым. Бу җәй айларын мин беркайчан онытмам! Ячменева Анастасия

## «Пушкин картасы» үсмерләрне мәдәниятле булырга өйрәтә

1 сентябрьдән Россиядә «Пушкин картасы» проекты гамәлгә керде. Бу карта белән 14-22 аралыгындагы яшьләр файдалана ала. Аларга дәүләт карамагында булган концерт залларына, театрларга, музейларга бару өчен менә дигән мөмкинлек бу . Гимназиянең 8-11 сыйныф укучылары « Пушкин картасы» буенча спектакль һәм концертларга барды инде.

Редактор: Якупова Г.Проект җитәкчесе: ШараповаН,Н.
Хөрмәтле укучылар, яңалыкларыгыз , тәкъдимнәрегез булса 3023001035@edu.tatar.ru электрон адресына җибәрә аласыз.